СОВЕТ КРАСНОГОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Мира, д.11А, п.с-за "Мамадышский", Мамадышский район, Республика Татарстан, 422165

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЫЗЫЛ ТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Тынычлык ур., 11А нче йорт, "Мамадыш" совхозы поселогы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422165

тел.(факс): (85563) 3-91-14; e-mail: KrGor.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение | Карар

"27" декабря 2023 г. | №4-30

# Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы N 1-7 карары белән расланган Кызыл Тау авыл җирлегендә муниципаль хезмәтләр турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

2023 елның 11 декабрендәге №02-01-19-2023 номерлы прокурор тәкъдиме, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль законнар, 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Кызыл Тау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тауавыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Та уавыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы N 1-7 карары (алга таба- Карар) белән расланган Кызыл Тау авыл җирлегендә муниципаль хезмәтләр турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Карарның 5.6. пунктында икенче җөмләне төшереп калдырырга;

1.2. Карарның 5.10 пунктның икенче абзацын үз көчен югалтты дип танырга;

1.3. 5.13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5.13. Муниципаль хезмәткәргә класс чины бирү турындагы карар, «Муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясындагы 13 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, класс чины бирү хакында тәкъдим барлык кирәкле документлар белән бергә җирле үзидарәнең класс чиннары бирергә вәкаләтле органына яисә вазыйфаи затына кергән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге каранның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тауавыл җирлеге башлыгы В.А. Гыйззәтуллина йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау
авыл җирлеге башлыгы, Советы рәисе / В. А. Гыйззәтуллина /

СОВЕТ КРАСНОГОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1626001027